ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2025 с.Старое Дрожжаное № 22

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы (06.05.2019 N 380, 16.04.2020 N 294, 01.09.2020 N 768, 03.11.2020 N 989, 21.07.2021 N 633, 26.07.2021 N 645, 30.10.2021 N 1030, 26.05.2022 N 489, 20.06.2022 N 587, 14.09.2022 N 1002, 30.11.2022 N 1268, 17.07.2023 № 846, 03.04.2024 № 215, 26.04.2024 № 283, 21.06.2024 № 447, 12.09.2024 № 766 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары кертелгән үзгәрешләр белән) карарының гамәлдә булуын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларына гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә әлеге карарда билгеләнгән җитди хезмәт шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 июнендәге 288 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов